СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

## РЕШЕНИЕ　　　　КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

20.10.2020　　　　с. Нижний Услон　　　　2-16

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020нче елның 6нчы августындагы 658нче номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге  Советының
2020нче елның 20нче октябрендәге
2-16нчы номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге  җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 14847 |

1.2. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советының
2020нче елның 20нче октябреннән
2-16нчы номерлы карарына
2 нче кушымта

Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләре күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 15300 |

2. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А. З. Шәйдуллин